ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2024 ел, 9 декабрь №263

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгының, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгының урынбасары, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторының, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 148 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 25 сентябрендәге 8290 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгының, Апас муниципаль районы башлыгының урынбасарының, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторының, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 148 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада - Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы хезмәте өчен түләү турында нигезләмәдә

1 пунктта таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 37036 |
| Башлык урынбасары | 33333 |
| контроль-хисап палатасы рәисе | 33333 |
| контроль-хисап палатасы удиторы | 25461 |

2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "а)ай саен акчалата бүләкләү:

| Вазыйфалар исемнәре | ай саен акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 109627 |
| Башлык урынбасары | 54000 |
| контроль-хисап палатасы рәисе | 54000 |
| контроль-хисап палатасы удиторы | 28771 |

2) 2 нче кушымтада - Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмәдә

2 пунктта «13323» санын «13990» санына алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
башлыгы-
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Советы рәисе

А. Г. Җиһаншин